**УКАЗ**
**ПРЕЗИДЕНТА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ПРЕЗИДЕНТЫ**
**УКАЗЫ**

# Об упразднении отдельных рабочих органов Совета Безопасности Республики Татарстан

В целях совершенствования деятельности Совета Безопасности Республики Татарстан **постановляю**:

1. Упразднить:

Межведомственную комиссию Совета Безопасности Республики Татарстан по безопасности в экономической и социальной сфере;

Межведомственную комиссию Совета Безопасности Республики Татарстан по общественной безопасности.

2. Внести изменение в Указ Президента Республики Татарстан от 1 февраля 2000 года № УП-61 «О межведомственных комиссиях Совета Безопасности Республики Татарстан» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 22 декабря 2005 года № УП-513, от 4 апреля 2006 года № УП-128, от 25 декабря 2007 года № УП-698 и от 27 сентября 2012 года № УП-786), исключив в пункте 1 слова «- по безопасности в экономической и социальной сфере;» и «- по общественной безопасности;».

3. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 22 декабря 2005 года № УП-513 «Об изменении составов Совета Безопасности Республики Татарстан, его отдельных рабочих органов и некоторых организационных вопросах их деятельности» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 4 апреля 2006 года № УП-128, от 12 января 2007 года № УП-4, от 25 декабря 2007 года № УП-698, от 3 июня 2009 года № УП-318 и от 27 сентября 2012 года № УП-786) следующие изменения:

а) пункт 7 признать утратившим силу;

б) подпункт «б» пункта 8 изложить в следующей редакции:

«б) в пункте 1 слова «- по оборонным вопросам и делам военнослужащих;» исключить;».

4. Признать утратившими силу пункты 1 и 2 Указа Президента Республики Татарстан от 3 июня 2009 года № УП-318 «Об изменении составов отдельных рабочих органов Совета Безопасности Республики Татарстан».

5. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
19 марта 2013 года
№УП-233

**УКАЗ**
**ПРЕЗИДЕНТА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ПРЕЗИДЕНТЫ**
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советының аерым эш органнарын бетерү турында**

Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Бетерергә:

Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советының Икътисадый һәм социаль өлкәдә куркынычсызлык буенча ведомствоара комиссиясен;

Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советының Җәмәгать куркынычсызлыгы буенча ведомствоара комиссиясен.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советының ведомствоара комиссияләре турында» 2000 елның 1 февралендәге ПУ-61 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2005 елның 22 декабрендәге ПУ-513 номерлы, 2006 елның 4 апрелендәге ПУ-128 номерлы, 2007 елның 25 декабрендәге ПУ-698 номерлы һәм 2012 елның 27 сентябрендәге ПУ-786 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән), 1 пункттагы «- икътисадый һәм социаль өлкәдә куркынычсызлык буенча;» һәм «- җәмәгать иминлеге буенча;» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Иминлек Советы, аның аерым эшче органнары составларын үзгәртү һәм алар эшчәнлегенең кайбер оештыру мәсьәләләре турында» 2005 елның 22 декабрендәге ПУ-513 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2006 елның 4 апрелендәге ПУ-128 номерлы, 2007 елның 12 гыйнварындагы ПУ-4 номерлы, 2007 елның 25 декабрендәге ПУ-698 номерлы, 2009 елның 3 июнендәге ПУ-318 номерлы һәм 2012 елның 27 сентябрендәге ПУ-786 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 7 пунктның үз көчен югалтуын танырга;

б) 8 пунктның «б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) 1 пунктта «- оборона мәсьәләләре һәм хәрби хезмәткәрләр эшләре буенча;» сүзләрен төшереп калдырырга;».

4. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советының аерым эш органнары составын үзгәртү турында» 2009 елның 3 июнендәге ПУ-318 номерлы Указының 1 һәм 2 пунктларының үз көчләрен югалтуларын танырга.

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2013 ел, 19 март
№ ПУ-233